# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№1** **24 ноябрь 2025 ел.**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Чемодурово авыл җирленең Алферовка торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2025 елның 24 ноябрендәге гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча түбәндәге сорау буенча йомгаклау беркетмәсе төзелде:

Сез «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлегенең Алферовка авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2025 елның 11 ноябрендәге 1 номерлы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлегенең Алферовка авылы торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында»гы 2025 елның 11 ноябрендәге 2 номерлы карарларына сорауны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә ризамы:

Сез Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлегенең Алферовка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасында укучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы гражданнардан тыш, 2026 елда 500 сум күләмендә бер тапкыр түләүне, 2 төркем инвалидлар өчен 250 сум күләмендә билгеләп, үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә ризамы?

-торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (юлларны һәм территорияләрне кардан чистарту, юл кырыйларын трактор белән чабу).

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмәгә яраклы рәвештә: сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 20 катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә 18 кеше катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" - 18 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" - 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Азнакай муниципаль районының авылы җирлегенең Чемодурово авыл җирленең Алферовка торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлегенең Алферовка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасында укучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы гражданнардан тыш, 2026 елда 500 сум күләмендә бер тапкыр түләүне, 2 төркем инвалидлар өчен 250 сум күләмендә билгеләп, үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә ризамы?

-торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (юлларны һәм территорияләрне кардан чистарту, юл кырыйларын трактор белән чабу).

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» http://aznakaevo.tatar.ru. һәм түбәндәге адрес буенча урнашкан: Алферовка авылы, Зеленая ур,5 мәгълүмат стендларында, урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чемодурово авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Чемодурово авыл җирлеге Башлыгы А.П. Курганская